**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

22.03.2019 ел

№ 156

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 143 номерлы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 32 бүлеге нигезендә, шулай ук «Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 143 номерлы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 11 сентябрендәге 187 номерлы, 2018 елның 30 октябрендәге 140 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарны түбәндәге эчтәлекле 2.2 пунктчасы белән тулыландырырга:

«2.2. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

1) 18 яшькә кадәр биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасына хокукы булган зат салым органына ташламалар бирү турында гариза һәм салым ташламасына хокукны раслый торган документларны тапшыра.

Салым ташламасы яшәү урыны буенча Түбән Биш авыл җирлегендә теркәлгән салым түләүчеләргә алар милкендәге салым салына һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган объектка карата салым суммасы күләмендә бирелә.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, әмма рәсми басылып чыккан көненнән соң бер айдан да иртәрәк түгел.

3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Д.В.Насертдинов**